| | | |
|---|---|---|
| МИНИСТЕРСТВО ЦИФРОВОГО РАЗВИТИЯ ГОСУДАРСТВЕННОГО УПРАВЛЕНИЯ, ИНФОРМАЦИОННЫХ ТЕХНОЛОГИЙ И СВЯЗИ РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН | | ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ДӘҮЛӘТ ИДАРӘСЕН ЦИФРЛЫ НИГЕЗДӘ ҮСТЕРҮ, МӘГЪЛҮМАТ ТЕХНОЛОГИЯЛӘРЕ ҺӘМ ЭЛЕМТӘ МИНИСТРЛЫГЫ |

**ПРИКАЗ** **БОЕРЫК**

23.09.2024 Казан ш. № п/193

Татарстан Республикасы бюджетына Татарстан Республикасы Дәүләт идарәсен цифрлы нигездә үстерү, мәгълүмат технологияләре һәм элемтә министрлыгы тарафыннан идарә ителә торган түләүләр буенча бурычларны түләтүгә өметсез дип тану турында карар кабул итү тәртибенә үзгәрешләр кертү турында

Боерык бирәм:

Татарстан Республикасы Дәүләт идарәсен цифрлы нигездә үстерү, мәгълүмат технологияләре һәм элемтә министрлыгының «Татарстан Республикасы бюджетына Татарстан Республикасы Дәүләт идарәсен цифрлы нигездә үстерү, мәгълүмат технологияләре һәм элемтә министрлыгы тарафыннан идарә ителә торган түләүләр буенча бурычларны түләтүгә өметсез дип тану турында карар кабул итү тәртибен раслау турында» 2023 елның 9 ноябрендәге п/242 номерлы боерыгы белән расланган Татарстан Республикасы бюджетына Татарстан Республикасы Дәүләт идарәсен цифрлы нигездә үстерү, мәгълүмат технологияләре һәм элемтә министрлыгы тарафыннан идарә ителә торган түләүләр буенча бурычларны түләтүгә өметсез дип тану турында карар кабул итү тәртибенә түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

2.2 пунктчаны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«2.2. «Бөлгенлек (банкротлык) турында» 2002 елның 26 октябрендәге 127-ФЗ номерлы федераль закон нигезендә гражданинның, шәхси эшкуарның банкротлык процедурасын тәмамлау – күрсәтелгән Федераль закон нигезендә аларның түләү йөкләмәсен үтәүдән азат ителгән бюджетка түләүләр буенча бурычлар өлешендә.»;

2.3 пунктчаны көчен югалткан дип танырга;

2.5 пунктчаны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«2.5. Штраф рәвешендә җәзага хөкем ителгән затларга карата амнистия турында яки ярлыкау турында актлар кулланылганда яки Министрлык бюджетка түләүләр буенча әҗәтләрне түләттерү мөмкинлеген югалта торган суд карары кабул

ителгәндә, шул исәптән аны түләттерүнең билгеләнгән срогы үтүгә бәйле рәвештә дә.»;

2.6 пунктчаны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«2.6. «Башкару эше турында» 2007 елның 2 октябрендәге 229-ФЗ номерлы федераль законның 46 статьясындагы 1 өлешенең 3 яисә 4 пунктында каралган нигез буенча башкару документын түләтүчегә кире кайтарганда, әгәр бурыч барлыкка килгән көннән бурычлыга карата бөлгенлек турында Россия Федерациясе законнарында билгеләнгән таләпләр күләменнән артмаса, башкаручы суд приставы тарафыннан башкару эшен тәмамлау турында карар чыгару (бөлгенлек) банкротлык турындагы эш буенча производство ачу өчен биш елдан артык вакыт узган булса.»;

түбәндәге эчтәлекле $2.6^{1}$ пунктчаны өстәргә:

«$2.6^{1}$. Бюджетка түләүләр түләүче затны банкрот дип тану турында гаризаны кире кайтару турында яисә банкротлык турында эштә кулланыла торган процедураларны үткәрүгә суд чыгымнарын каплау өчен җитәрлек күләмдә акча булмау сәбәпле банкротлык турындагы эшне туктату турында суд акты кабул итү»;

4.3 пунктчада:

дүртенче абзацта «2.3 пунктчасында» сүзләрен «2.2 пунктчасында» сүзләренә алмаштырырга;

җиденче абзацта «2.6 пунктчасында» сүзләрен «2.6, $2.6^{1}$ пунктчаларында» сүзләренә алмаштырырга;

сигезенче абзацта «2.6 пунктчасының өченче абзацында» сүзләрен «$2.6^{1}$ пунктчасында» сүзләренә алмаштырырга;

түбәндәге эчтәлекле $10^{1}$ пунктын өстәргә:

«$10^{1}$. Комиссия утырышы йомгаклары буенча, Тәртипнең 10 пунктының өченче абзацында күрсәтелгән очракта, утырыш уздырылган көннән алып ун эш көне эчендә Татарстан Республикасы бюджетына түләүләр буенча бурычны түләтүгә өметсез дип тану турында карар проекты әзерләнә.»;

түбәндәге эчтәлекле 12 пункт өстәргә:

«12. Тәртипнең 10 пунктының дүртенче абзацында күрсәтелгән очракта, комиссия утырышы беркетмәсендә Татарстан Республикасы бюджетына түләүләр буенча бурычны түләтүгә өметсез дип тану өчен нигезләр булмау турындагы мәгълүмат чагылдырыла. Беркетмә утырышта рәислек итүче һәм комиссия секретаре тарафыннан имзалана һәм министрга хәбәр итү өчен җибәрелә.».

Министр А.Р. Хәйруллин